**Балачак бәйрәмнәре**

1. Балачакның урамнарын
Кем генә әйләнмәде?
Әкият иленә илтә
Балачак бәйрәмнәре.

Кушымта:
Әй, балачак,балачак!
Истә мәңге калачак.
Иң кадерле истәлекләр
Гел озатып барачак.

2. Хәтфә сыман үләнендә-
ялан тәпи йөгерәм.
Туган телемдә кабатлыйм
Әти, Әни, Илгенәм.

Кушымта:
Әй,балачак,балачак!
Истә мәңге калачак.
Иң кадерле истәлекләр
Гел озатып барачак.

3. Куллар канат булып китә
Хыяллар биек-биек.
Яшик туган җиребезне
Кадерләп кенә сөеп

Кушымта:
Әй,балачак бәйрәмнәре!
Истә мәңге калачак.
Иң кадерле истәлекләр
Гел озатып барачак.